**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 111 «03» сентябрь 2018 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"Сез, 2019 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

3) халыкны су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү уртак чикләрендә оештыру;

4) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;

5) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

-ТР. Азнакай районы,Урсай авылы, Үзәк ур., 65;

-ТР, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури ур., 31,

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Рәис И.А.Абдуллин